РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» декабрь 2020 г. г. Альметьевск №16

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 39 номерлы «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр өчен аренда түләве буенча естәмә коэффициентны раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 01 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 09 февралендәге 74 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре уставы нигезендә, норматив-хокукый актлар мониторингы кысаларында,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 39 номерлы «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр өчен аренда түләве буенча өстәмә коэффициентны раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының икътисадый үсеш һәм эшкуарлык мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә (Великий С.И.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»

Зак. № 1145-50